**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 10 июнь № 393

г. Казань

Төбәк әһәмиятендәге мәдәни мирас объектын яки җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объектын Россия Федерациясе халыклары мәдәни мирас объектларының (тарихи һәм мәдәни ядкәрләренең) бердәм дәүләт реестрына кертү турында карар кабул итү тәртибе хакындагы нигезләмәне раслау турында

«Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкәрләре) турында» 2002 ел, 25 июнь, ФЗ-73 нче Федераль закон, «Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектлары турында» 2005 ел, 1 апрель, ТРЗ-60 нчы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән Төбәк әһәмиятендәге мәдәни мирас объектын яки җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объектын Россия Федерациясе халыклары мәдәни мирас объектларының (тарихи һәм мәдәни ядкәрләренең) бердәм дәүләт реестрына кертү турында карар кабул итү тәртибе хакындагы нигезләмәне расларга.
2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2016\393.docx

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2016 ел, 10 июнь, 393 нче
карары белән расланды

**Төбәк әһәмиятендәге мәдәни мирас объектын яки җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объектын Россия Федерациясе халыклары мәдәни мирас объектларының (тарихи һәм мәдәни ядкәрләренең) бердәм дәүләт реестрына кертү турында карар кабул итү тәртибе хакында нигезләмә**

1. Әлеге Нигезләмә «Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкәрләре) турында» 2002 ел, 25 июнь, ФЗ-73 нче Федераль закон, «Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектлары турында» 2005 ел, 1 апрель, ТРЗ-60 нчы Татарстан Республикасы Законы нигезендә эшләнде.

2. Нигезләмә Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең вәкаләтле органы тарафыннан мәдәни мирас объектын Россия Федерациясе халыклары мәдәни мирас объектларының (тарихи һәм мәдәни ядкәрләренең) бердәм дәүләт реестрына (алга таба – Реестр) төбәк әһәмиятендәге мәдәни мирас объекты яки җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объекты буларак кертү турында карар кабул итү тәртибен билгели.

3. Мәдәни мирас объектын Реестрга төбәк әһәмиятендәге мәдәни мирас объекты яки җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объекты буларак кертү турындагы яисә әлеге объектны Реестрга кертүдән баш тарту хакындагы карар «Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкәрләре) турында» 2002 ел, 25 июнь, ФЗ-73 нче Федераль законның (алга таба – Федераль закон) 18 статьясында, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт тарихи-мәдәни экспертизасы турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2009 ел, 15 июль, 569 нчы карары белән расланган Дәүләт тарихи-мәдәни экспертизасы турындагы нигезләмәдә (алга таба – Экспертиза турында нигезләмә) билгеләнгән таләпләргә ярашлы рәвештә рәсмиләштерелгән дәүләт тарихи-мәдәни экспертизасы бәяләмәсе (алга таба – экспертиза бәяләмәсе) нигезендә кабул ителә.

4. Дәүләт тарихи-мәдәни экспертизасын (алга таба – экспертиза) үткәрү Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы (алга таба – Министрлык), дәүләт хакимиятенең башка мәнфәгатьле органы, җирле үзидарә органы, юридик яки физик зат (алга таба – заказчы) башлангычы буенча гамәлгә ашырыла.

5. Мәдәни мирас объектын Реестрга төбәк әһәмиятендәге мәдәни мирас объекты яки җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объекты буларак кертү турындагы яисә әлеге объектны Реестрга кертүдән баш тарту хакындагы карар кабул итү өчен заказчы (заказчы Министрлык булган очраклардан тыш) Экспертиза турындагы нигезләмәнең 28 нче пункты нигезендә экспертиза бәяләмәсен аңа теркәлә торган документлар һәм материаллар белән Министрлыкка кертә.

6. Министрлык кертелгән экспертиза бәяләмәсен, теркәлә торган документларны һәм материалларны Экспертиза турындагы нигезләмәдә күрсәтелгән таләпләргә туры килү-килмәвен тикшерә һәм, туры килгән очракта, аны Министрлыкның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында, кертелгән экспертиза бәяләмәсен теркәгән көннән соң биш эш көненнән дә соңга калмыйча, җәмәгатьчелек фикер алышуы өчен билгеләнгән тәртиптә урнаштыра.

7. Кертелгән экспертиза бәяләмәсе, аңа теркәлә торган документлар һәм материаллар Экспертиза турындагы нигезләмәдә күрсәтелгән таләпләргә туры килмәгән очракта, экспертиза бәяләмәсе һәм аңа теркәлә торган документлар һәм материаллар теркәгән көннән соң биш эш көненнән дә соңга калмыйча Министрлык тарафыннан, кайтару сәбәпләрен күрсәтеп, заказчыга кире кайтарыла.

8. Экспертиза бәяләмәсен, аңа теркәлгән документларны һәм материалларны, шулай ук җәмәгатьчелек фикер алышканда кертелгән тәкъдимнәрне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча Министрлык экспертиза бәяләмәсен теркәгән көннән соң 25 эш көне эчендә түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

мәдәни мирас объектын Реестрга төбәк әһәмиятендәге мәдәни мирас объекты яки җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объекты буларак кертүнең нигезле булуы турындагы һәм мәдәни мирас объектын Реестрга төбәк әһәмиятендәге мәдәни мирас объекты яки җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объекты буларак кертү хакындагы экспертиза бәяләмәсендә бәян ителгән нәтиҗәләр белән риза булу турында;

мәдәни мирас объектын Реестрга төбәк әһәмиятендәге мәдәни мирас объекты яки җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объекты буларак кертүнең нигезле булмавы турындагы һәм мәдәни мирас объектын Реестрга төбәк әһәмиятендәге мәдәни мирас объекты яки җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объекты буларак кертүдән баш тарту хакындагы экспертиза бәяләмәсендә бәян ителгән нәтиҗәләр белән риза булу турында;

мәдәни мирас объектын Реестрга төбәк әһәмиятендәге мәдәни мирас объекты яки җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объекты буларак кертүнең нигезле булуы хакындагы экспертиза бәяләмәсендә бәян ителгән нәтиҗәләр белән риза булмау турында;

мәдәни мирас объектын Реестрга төбәк әһәмиятендәге мәдәни мирас объекты яки җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объекты буларак кертүнең нигезле булмавы хакындагы экспертиза бәяләмәсендә бәян ителгән нәтиҗәләр белән риза булмау турында.

9. Әлеге Нигезләмәнең 8 нче пунктындагы дүртенче һәм бишенче абзацларда күрсәтелгән карарлар түбәндәге очракларда кабул ителә:

экспертиза бәяләмәсенең мәдәни мирас объектларын дәүләт саклавы өлкәсендәге Россия Федерациясе законнарына туры килмәве;

экспертиза бәяләмәсен рәсмиләштергән көннән соң өчьеллык вакыт үтүе;

экспертиза бәяләмәсен имзалаган экспертка карата Экспертиза турындагы нигезләмәнең 8 нче пунктында каралган хәлләр ачыклануы;

экспертиза үткәрүнең билгеләнгән тәртибен бозу;

экспертиза үткәрү өчен Экспертиза турындагы нигезләмәнең 16 нчы пунктында күрсәтелгән, үз эченә дөрес булмаган мәгълүматлар алган документлар тапшыру.

10. Әлеге Нигезләмәнең 8 нче пунктындагы дүртенче һәм бишенче абзацларда күрсәтелгән карарлар кабул ителгән очракта, Министрлык, экспертиза бәяләмәсен теркәгән көннән соң 45 эш көненнән дә соңга калмыйча, әлеге карарның мотивлашкан сәбәпләрен күрсәтеп, заказчыга экспертиза бәяләмәсенең бер нөсхәсе, аңа теркәлә торган документлар һәм материаллар белән бергә язма рәвештә хәбәрнамә җибәрә (бирә).

11. Министрлыкның күрсәтмәләрен һәм тәкъдимнәрен исәпкә алып эшләнеп беткән экспертиза бәяләмәсен Министрлык әлеге Нигезләмәдә билгеләнгән тәртиптә һәм вакытларда тагын бер кат карап тикшерә.

12. Әлеге Нигезләмәнең 8 нче пунктындагы дүртенче һәм бишенче абзацларда күрсәтелгән карарлар кабул ителгән очракта, Министрлык үз инициативасы буенча яисә мәнфәгатьле зат гаризасы буенча Экспертиза турындагы нигезләмәдә билгеләнгән тәртиптә яңадан экспертиза билгеләргә хокуклы.

13. Министрлык «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә экспертиза бәяләмәсе буенча җәмәгатьчелек фикер алышуы вакытында кертелгән тәкъдимнәр җыелмасы урнаштырылган мизгелдән соң 10 эш көне эчендә, мәдәни мирас объектларын саклау органының позициясен күрсәтеп, төбәк әһәмиятендәге мәдәни мирас объектын яки җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объектын Россия Федерациясе халыклары мәдәни мирас объектларының (тарихи һәм мәдәни ядкәрләренең) бердәм дәүләт реестрына кертү турында боерык проектын әзерли, һәм ул түбәндәгеләрне күздә тотарга тиеш:

объект исеме турында мәгълүматлар;

объектның барлыкка килү вакыты яки аны төзегән дата турында, объектны үзгәртүләрнең (үзгәртеп корулар) төп даталары һәм (яки) аңа бәйле тарихи вакыйгалар даталары хакында мәгълүматлар;

объектның урнашкан урыны турында мәгълүматлар (объектның адресы яки, адресы булмаса, объект урнашкан урын тасвирламасы);

тарихи-мәдәни әһәмияте категориясе турында мәгълүматлар;

объектның төре турында мәгълүматлар;

мәдәни мирас объекты территориясе чикләре тасвирламасы (әлеге чикләр урнашкан урынның текстта тасвирламасын теркәп), күчемсез мөлкәт объектлары дәүләт кадастрын алып бару өчен билгеләнгән координатлар системасында әлеге чикләрнең үзенчәлекле нокталары координатлары исемлеге;

мәдәни мирас объектын саклау предметы турында мәгълүматлар.

14. Аның нигезендә мәдәни мирас объекты Реестрга җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объекты буларак кертелә торган карар җирле үзидарә органы белән килештерү буенча Министрлык тарафыннан кабул ителә. Әлеге Нигезләмәнең 13 нче пунктында күрсәтелгән боерык проектын әзерләү вакыты чыкканнан соң, Министрлык аны килештерүгә җибәрә.

15. Министрлык әлеге Нигезләмәнең 8 нче пунктындагы икенче һәм өченче абзацларда күрсәтелгән карарлар кабул ителгән көннән соң биш эш көненнән дә

соңга калмыйча, аңа карата карар кабул ителгән объектның милекчесенә яисә башка законлы хуҗасына, шулай ук әлеге объект территориясе чикләрендәге җир кишәрлегенең милекчесенә яисә башка законлы хуҗасына кабул ителгән карар турында язма рәвештә хәбәрнамә җибәрә.

16. Министрлык әлеге Нигезләмәнең 8 нче пунктындагы икенче һәм өченче абзацларда күрсәтелгән карарлар кабул ителгән көннән соң биш эш көненнән дә соңга калмыйча, кадастр исәбе органына әлеге карарлар күчермәләрен, шулай ук күчемсез мөлкәт объектлары дәүләт кадастрын алып бару өчен билгеләнгән координатлар системасында әлеге чикләрнең үзенчәлекле нокталары координатлары исемлеге белән төбәк әһәмиятендәге яки җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объекты территориясе чикләре урнашкан урынның текстта һәм график тасвирламасын үз эченә алган мәгълүматлар җибәрә.

17. Министрлык әлеге Нигезләмәнең 8 нче пунктындагы икенче абзацта күрсәтелгән карар кабул ителгән көннән соң 30 эш көненнән дә соңга калмыйча, төбәк әһәмиятендәге яки җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объектын Реестрда теркәү өчен, Федераль законның 20 статьясындагы 2 нче пунктта күрсәтелгән мәгълүматларны Россия Федерациясе Мәдәният министрлыгына җибәрә.

18. Әлеге Нигезләмәнең 8 нче пунктындагы икенче – бишенче абзацларда күрсәтелгән карарлар Министрлыкның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырылырга тиеш.

_______________________________

F:\KARAR\2016\393_1.docx